ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№__307_ от «_04__»____04_____2018 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының «Торак биналарны яшәү урыннары итеп тану,биналарның яшәү өчен яраклы яки яраксыз булуын билгеләү, авария хәлендәге күпфатирлы торак биналарны сүтү, торак биналарны торак булмаган бина итеп күчерү мәсьәләләрен карау һәм өйрәнү буенча ведомствоара комиссиясе составын раслау турында» 18.06.2009 ел 625 санлы карары белән расланган биналарны яшәү урыннары итеп тану, биналарның яшәү өчен яраксыз булуын билгеләү һәм авария хәлендәге күпфатирлы торак биналарны сүтелергә тиешле дип тану турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Мамадыш районы прокуроры , юстиция киңәшчесе Р.И. Надыршинның 2018 елның 12 мартыннан 02-01-18-18 сан астындагы тәкъдимен караганнан соң, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының «Торак биналарны яшәү урыннары итеп тану,биналарның яшәү өчен яраклы яки яраксыз булуын билгеләү, авария хәлендәге күпфатирлы торак биналарны сүтү, торак биналарны торак булмаган бина итеп күчерү мәсьәләләрен карау һәм өйрәнү буенча ведомствоара комиссиясе составын раслау турында» 18.06.2009 ел 625 санлы карары белән расланган биналарны яшәү урыннары итеп тану, биналарның яшәү өчен яраксыз булуын билгеләү һәм авария хәлендәге күпфатирлы торак биналарны сүтелергә тиешле дип тану турындагы Нигезләмәгә «Торак биналарны яшәү урыннары итеп тану,биналарның яшәү өчен яраклы яки яраксыз булуын билгеләү, авария хәлендәге күпфатирлы торак биналарны сүтү, торак биналарны торак булмаган бина итеп күчерү мәсьәләләрен карау һәм өйрәнү буенча ведомствоара комиссиясе составын раслау турында» 18.06.2009 ел 625 санлы карарының 1 бүлеге, 7 пунктының 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә: «Комиссия эшенә киңәш бирү тавышы хокукы белән торак урыны милекчесе(аларга вәкаләтле зат) җәлеп ителә, аңа торак булмаган биналарга һәм торак булмаган биналарга торак урын, торак бинаны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә тиешле дип тану, торак йортларны үзгәртеп кору һәм (яки) үзгәртеп планлаштыруга бәйле мәсьәләләрне

өйрәнү һәм карау буенча ведомствоара комиссиясенең утырышы вакыты һәм урыны турында алдан хәбәр ителергә тиеш, ә кирәкле очракларда – хәлиткеч тавыш хокукы булган проект-тикшеренү оешмаларының квалификацияле экспертлары да чакырыла».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.К. Мөхәмәтҗановка йөкләргә.

Җитәкче И.М. Дәрҗеманов